Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи

# КҮП ХАТЫНЛЫК

Түбән Кама 2011

ББК 86.38
© Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи
e-mail: mullaniyaz@mai.ru

بسم الله الرحمن الرحيم

# Кереш сүз

إن الحمد لله نحمده و نستعينه و نستغفره و نعوذ بالله من شرور أنفسنا و سيئات أعمالنا من يهده الله فلا مضل له و من يضلل فلا هادي له و أشهد أن لا إله إلا الله وحده لا شريك له و أشهد أن محمدا عبده و رسوله، أما بعد...

Безгә кадәр булган заманалардан башлап инде христиан-Аурупа фикерләренең үсентесе үсеп чыкты. Ул фикерләр хәзерге вакытларда көчәеп, мөселманнар арасында киң тамыр җәеп килә. Күп кенә мөселманнар бу фикерләрнең Ислам гакыйдәсенә каршы килгәнлеген аңламыйлар, яки аңларга да теләмиләр. Шуларның берсе; мөселманга дүрт хатын алуга каршы булган фикерләр.

Ләгънәт кылынганнар һәм дуңгыз ашаучылар төрле юллар белән безгә үзләренең батыл фикерләрен кертергә телиләр. Шушы пычрак фикерләрдән Ислам гакыйдәсен пакьләргә вә якларга тиеш булган мөселманнар, үзләре дә сизмичә, кайвакыт шул фикерләрне таратучы булалар. Хәтта, кайбер хәзрәтләр белеп тә, белмичә дә менбәрләрдән күп хатынлыкка каршы вәгазьләр сөйләүләре ихтимал. Болар һәммәсе дә мөселманнарның гыйлемгә һәм Ислам гакыйдәсенә зур әһәмият бирмәгәненнән чагыла. Чөнки, Аллаһ хөкемнәрендә уйламыйча нәрсәдер әйтергә куркырлар иде.

Ике, өч, дүрт хатынга никахланырга каршы булучылар үзләренең сүзләрен төрлечә исбатлап, акланырга тырышалар, мәсәлән:

Имеш, алар гаиләләргә һәм балаларга кызгану белдереп, күп хатынлык хатыннарның хокукын кимсетә вә балаларның тәрбиясез сукбайларга әйләнүенә сәбәп булалар. Бәлки, берничә хатын алучы ир-атларның күбесе гаиләләрен тәэмин итә алмаган фәкыйрьләр диләр.

Әгәр дә, аларның кулларыннан килсә, байларга гына рөхсәт итеп, башкаларга тыярлар иде. Бу сүзләрне әйтүче надан кемсәләр, чепчи ялганчылар. Чөнки алар Аллаһның ризыкландыручы икәнлеген инкяр иткән булалар, һәм дә расүлебезнең бер кешегә җиткән ризык — икегә, икегә җиткәне — дүрткә, дигән кебек сүзләренә ышанмый булып чыгалар.

Шулай ук, алар күп хатынлык гаделлек шарты белән генә ярый, ә Аллаһ Коръәндә гадел була алмыйсыз дип әйтте диләр. Һәм сүзләрен кайбер аять өлеше белән исбатлап, һәм аятьның калган өлешен белеп яки белмичә төшереп калдыралар. **«Сез бик нык хирыс булсагыз да, хатыннар арасында гаделлек кыла алмыйсыз»**[1] дигән аятьнең беренче өлешен әйтеп, **«Берсен (ирсез) асылынып калган хәлдә калдырган кебек, икенчесенә тулысы белән авышып бетмәгез»** дигәнне төшереп калдыралар. Бу кемсәләр, кайбер аятьләргә ышанып, икенчеләренә көферлек иткән кебек булалар!

Кайберәүләр бу гамәлне мөбәх-рөхсәт ителгән генә диләр. Әйе, ләкин әгәр дә бер хатын гына канәгатьләндермичә чит хатыннарга карау, яки чуалу кебек куркынычлык булса, ул вакытта әмер ителгән вә боерылган мөбәхка әйләнә. Шулай итеп, бәгъзе кемсәләр әйткәнчә, ул зарури булганда гына мөбәх-рөхсәт ителгән түгел, бәлки зарури булганда әмер ителгән мөбәх санала.

Бу аятьта: **«Әгәр гаделлек кыла алмабыз дип курыксагыз, бергә генә никахланыгыз»,** — дигән шарт, ул шәрьгый - солтан яки казый карамагына караган - шарт булып килми, ә бәлки шәхси - һәр шәхеснең үзенә кагылышлы - шарт булып килә.

Шулай ук, хатыннарга карата гаделлекне эстәп килгән әмер-боерык, ул ир-атның үзендәге хәленә карап яки башка төрле сәбәпләр белән үзгәрергә мөмкин. Ягъни, ир-ат ике, өч, дүрт хатын алганда бай булса да, бөлгенлеккә төшеп фәкыйрь булуы мөмкин һ.б. Шуның

1 ән-Нисә 129

өчен дә, бу гаделлек никахның шарты булып килми, бәлки өйләнүченең үзе белән бәйле шарт.

Өйләнүче ир-ат күңеле белән гадел була алмасмын дип уйлауы ихтимал, ләкин өйләнгәч аның күңелендәге уйлары дөрес булмыйча, ул хатыннары арасында гаделлек белән яшәүе мөмкин. Шулай ук, киресе дә, ягъни берәү гадел булам дип өйләнеп, гадел булмауы ихтимал, һәм моның өчен гөнаһы кешенең үзенә була.

Үзләренең нәфселәренә, гакылларына ияреп, Коръән һәм Сөннәт белән уйнаучылар күп хатынлыкка каршы, Гали ﵁ Фатыймә белән яшәгәндә, аның Әбү Җәһелнең кызын сорау вакыйгасын китерәләр. Бу хакта пәйгамбәребездән ﷺ соралгач, ул: ***«Рөхсәт итмим! Рөхсәт итмим! Рөхсәт итмим! Иллә-мәгәр Гали бин Әбү Талиб минем кызымны аерып аларның кызына өйләнсә генә! Чөнки ул минем бер кисәгем. Аны борчыган нәрсә – мине дә борчый, һәм аны авырттырган нәрсә – мине дә авырттыра!»,*** — диде[2]. Алар хәдиснең башка тарафларын алмыйча, шушылай кыскартып кына, пәйгамбәр ﷺ күп хатынлыкны тыя дип билгеләделәр. Ләкин пәйгамбәр ﷺ бу хәдиснең башка тарафында: ***«Мин хәләлне хәрам кылмыйм, һәм хәрамны хәләл кылмыйм. Ләкин, Аллаһ белән ант итәм! Аллаһ расүленең кызы белән Аллаһ дошманының кызы беркайчан да (бер кешедә) бергә булмаячаклар!»,*** — диде[3].

Әй мөселманнар! Сезне шәйтан һәм аның иярченнәре алдамасын! Алар безгә Аллаһ хәләл кылган нәрсәләрне яманлап күрсәтеп, хәрамнарны матурлап күрсәтмәкче булалар. Бу, күп хатынлык мәсьәләсе дә мөбәх яки мөбәх түгел дигәнгә генә бәйләнеп калмый, ә бәлки ул Ислам гакыйдәсенең асылы вә нигезе белән бәйле мәсьәлә.

---

2 Бохари 5230
3 Бохари 3110

# Мәхәббәт серләре

Өйләнешү, Аллаһ тәгаләнең кешеләргә биргән зур нигъмәтләренең берсе булып тора. Ул, Исламда олы урын тота һәм зур вә куркыныч килешүләрнең берсе булып санала. Аллаһ әйтте:

وَأَخَذْنَ مِنْكُمْ مِيثَاقًا غَلِيظًا

**«Һәм алар (хатыннар) сездән (никах вакытында) каты-авыр гаһед алдылар»** (ән-Нисә 21)

Гыйлем әһелләре бу хакта болай диде:

— **«Каты-авыр гаһед»** — ул, никах килешүе. Бу килешү белән ике кешенең бер-берсенә хәрам булган мөгамәләләре бетә, ягъни хәләлгә әйләнә. Аның белән ике кеше арасында үзара аңлашу, бәйләнеш, мәхәббәт белән дәвамлы иттифакъ төзелә. Ир белән хатын арасындагы мәхәббәтнең иң зур вә иң күркәм сәбәпләренең берсе, ул – җенси якынлык кылу. Алар арасындагы тулы ләззәт вә бәхет иллә-мәгәр Аллаһ хәләл кылган җенси якынлык белән генә була.

Имам Әхмәд болай диде: «Буйдаклыкның Ислам диненә бер катнашы да юк! Пәйгамбәр ﷺ ундүрт хатынга өйләнде, ә ул вафат булганда аның тугыз хатыны калды. Әгәр дә кешеләр никахтан читләшсәләр, бу вакытта нәселләр өзелер иде, җиһәд һәм хаҗлар туктар иде һ.б. Ул ﷺ никахлануны сайлый һәм аңа өнди иде, шунлыктан да, кем дә кем пәйгамбәрнең сөннәтеннән читләшсә, ул адашып хаклыктан тайпылган булды».

Ибен әл-Кайим болай диде: «Әбү Мөслим әл-Хәүләни әйтте: «Әй кешеләр! Яшьләрегезне өйләндерегез вә кияүгә бирегез! Хакыйкатьтә, пәйгамбәр ﷺ үзенең хатыннарын бер төн эчендә әйләнеп чыга иде, һәм күп кенә вакытларда аларның барысы белән дә йоклап чыккач бер генә госел коена торган иде. Аның мондый көчле булуы гаҗәеп түгел, хакыйкатьтә, Аллаһ барча нәрсәгә дә

кадир. Пәйгамбәребезгә җенси якынлык кылуда кырык ир-ат көче бирелгән иде».

Яшь вакыттагы көчле шәһвәтлекне тыерга бик авыр. Бигрәк тә бу илдә. Шуңа да, аның өчен алдан әзерлек кирәк. Ягъни ата-аналар яшьләрне өйләндерү вә кияүгә бирү хәстәрен алдан ук күрергә тиеш.

Ир белән хатын арасында җенси якынлыктан да ныграк ләззәтле вә рәхәтлек таба торган нәрсә юктыр. Шуның өчен дә алар бер-берсен аңлап вә килешеп тормыш итәргә тиеш. Күп кенә талаклар да шушы мәсьәләне тиешлечә аңламаганнан яки начар кулланганнан яки ләззәтне татымаганнан килеп чыга. Монда пәйгамбәребезнең ﷺ ошбу хәдисен китерү бик тә урынлы булса кирәк:

***– Пәйгамбәребез ﷺ янына Рифәга әл-Куразиның хатыны килеп: «Мин Рифәгада идем, ә ул мине тулысы белән талак кылып җибәрде, шуннан соң мин Габдуррахмән бин әз-Зүбәйргә чыктым, ә аныкы (асылынып торган) кием чугы кебек кенә», – диде. Пәйгамбәребез ﷺ аңа: «Синең киредән Рифәгага кайтасың киләме? Юк! Син аның балын татыганчы һәм ул синең балыңны татыганчы кире кайта алмыйсың», – диде[4]...***

Ир белән хатын арасында җенси мөнәсәбәтнең мөһимлегеннән чыгып, сәләфләрдән Мөхәммәд бин әл-Мүнкәдир дога кылганда дәимән болай дип әйтә иде:

— «Әй Аллаһ! Минем җенес әгъзамны куәтле ит, чөнки аның куәтлегендә минем гаиләм өчен төзеклек бар»[5]

Зирәк вә үткен карашлы ир-ат үзе турында гына уйламыйча, бәлки хатынын барча яклап та канәгатьләндерүне һәм гаиләне төзек вә тигез кылуны хәстәрли. Шулай ук, зирәк хатын-кыз да.

4 Бохари 2639, 5260. Мөслим 1433
5 Ибен әл-Кайим «Раудаһ әл-Мүхиббин»

Әл-Ләйс бин Сәгъд болай дип әйтә торган иде:

— «Әй Аллаһ! Минем җенес әгъзамның асылын ныклы кыл, башын күтәренке кыл, керүен вә чыгуын җиңел кыл һәм аның ләззәтен татыт. Әй Раббым! Миңа, Үзеңнең юлыңда сугышучы изге балалар бир»[6]

Әгәр дә якынлык кылуда берәр төрле авырлык яки зарури хәләт булса, моннан арыну өчен ир-атлар аны дәвалауда яки искә алып дога кылуда оялмыйлар иде.

Билгеле гыйлем иясе, имам Габдуллаһ бин Рабига хакында болай риваять ителде: «Ул бик тә көчле булып, җенес әгъзасы да дәими тора торган хәлдә иде. Шул сәбәпле аңа бер хатыны да түзә алмыйча гел талак сорый торган булдылар. Бигрәк тә, әгәр аларның җенес әгъзалары тар булса. Габдуллаһ өйләнгәннән соң, аның хатыннары берничә көн генә сабыр итәләр иде. Бервакыт Зәйнәб бинт Гомәр бин Әбү Сәләмә иптәшләреннән ул хатыннар хакында: «Ни өчен бу хатын-кызлар барысы да Габдуллаһтан качалар?», — дип сорады. Аңа: «Алар аңа сабыр итә алмыйлар», — дип җавап бирделәр. Зәйнәб аларга: «Ник соң ул миңа өйләнми? Аллаһ белән ант итәм! Мин бик тә чибәр хатын, билем нечкә, арт саным зур һәм җенес әгъзам да тиешлечә», — диде. Габдуллаһ бин Рабига Зәйнәбкә өйләнде, ул иренә сабыр итте һәм аларның алты баласы булды».[7]

Шик юк, әгәр дә ир-ат хатынына карата җенси мөгамәләдә ваемсыз булса, бу хатын-кызга бик зур уңайсызлыклар тудыра һәм мәхәббәтнең юкка чыгуына сәбәп була.

Җенси мөгамәләдә ирләрнең дә, хатыннарның да хокуклары бертигез каралган. Алар бер-берсе белән ләззәтләнүдә шәригать чигеннән чыкмыйча, ничек теләсәләр шулай рәхәтләнергә тиешләр. Монда кайбер гыйлем ияләренең сүзләрен искә алып китү мөһим:

---

6 Ибен әл-Кайим «Раудаһ әл-Мүхиббин»

7 Ибен әл-Кайим «Раудаһ әл-Мүхиббин»ның «Дәүә әл-Мүхиббин» бүлеге

— «Ир-ат хатынын ничек ризык белән туйдыра торган булса, җенси ләззәт белән дә шулай ук туйдырырга тиеш»[8]

— Мине, хатынының дәвасын белгән тапкыр вә зирәк ир-ат шатландыра. Әгәр дә алар арасында ачуланышу яки үпкә булса, бу ир-ат хатыны белән җенси мөнәсәбәт аша татулыкны эсти торган иде. Бервакыт шундый ачуланышудан соң хатыны аңа: «Әгәр дә безнең арада ачуланышу килеп чыкса, син һәрвакыт, мин кире кага алмаслык вә сине яраттыра торган шәфәгатьче (җенси мөгамәлә) белән килә торган булдың»[9]

Әйтеп узарга кирәк: хатын-кызның иреннән ачык рәвештә җенси якынлык эстәвендә, шәригать буенча бернинди дә гаеп юк. Чөнки, пәйгамбәребез вакытында хатын-кыз аның ﷺ янына килеп иренең җенси көчсезлегеннән зарлана торган булды, һәм расүлебез аларны ошбу сәбәпле аерылу белән хөкем итте.[10]

Шулай ук, хатын-кыз өйдә ире алдында бизәнеп вә матурланып аны үзенә кызыктыруы, динебезгә муафыйк нәрсә. Ә инде хәзерге вакытларда, хәтта мөселман хатыннары арасында да бик еш күренә башлаган, бизәнептөзәнеп өйләреннән чыгулары, һәм чит ир-атларга матур булып күренергә, аларны аздырырга, гөнаһка этәрергә теләүләре, динебезнең бер кагыйдәсенә дә туры килми. Ә киресенчә, хатын-кызларның андый бизәнүләре шелтәләнә һәм гөнаһлы санала.

Бу мәсьәләбезне ибен әл-Кайимның сүзләре белән тәмамлыйбыз:

— «(Җенси мөгамәләдә) тәннең һәрбер өлеше үзенә тиешлене алмыйча, ләззәтләнү тулы була алмый. Күз, яратканга карап ләззәтләнә. Колак, яратканның сүзләрен тыңлап ләззәтләнә. Борын, яраткан кешедән килгән хушбуйны иснәп ләззәтләнә. Авыз-ирен, аны үбеп

8 Ибен әл-Кайим «Раудаһ әл-Мүхиббин»
9 Ибен әл-Җәүзи «Әхбәр ән-Нисә»
10 Искә алынганча, бу Рифәганың хатыны һәм шулай ук башка очраклар

ләззәтләнә. Кул, аны тотып-сыпырып ләззәтләнә. Шулай итеп, тәннең һәрбер әгъзасы үзенә тиешлесен таләп итә. Әгәр дә, шушыларның берәрсе генә югалса, күңел аны эстәүдән туктамый һәм тулысынча тынычлык таба алмый. Ир-атның күңел-нәфсесе хатын-кызда тынычлык тапкан өчен, хатын тынычлык табу иясе дип аталды. Аллаһ тәгалә болай диде, мәгънәсе: **«Дәхи, Аллаһның кодрәтенә булган дәлилләрдән: сезнең өчен Аллаһ үзегездән хатыннар халикъ кылды, ул хатыннарда тынычлык табу өчен...»[11]** Бәлки, шуңа да көндезге җенси якынлык кылу кичкесенә карганда хәерлерәктер дә».

Аннары дәвам итеп әйтте: «Раббының бу нәрсәдән риза булуы өчен, мәхәббәтлеләр шатлана. (Чөнки Аллаһ ир белән хатынның җенси якынлыгы өчен әҗер-савап яза). Бу нигъмәтләрнең камиллыгы. Шунлыктан да, шәйтанның иң яраткан нәрсәсе — ир белән хатынны аеру, һәм аларны хәрам юлга (зинага) этәрү.

Шулай итеп, ир белән хатынның җенси якынлык кылулары Аллаһка сөйкемле гамәлләрдән саналса, Аның дошманы булган иблискә ир белән хатынның җенси якынлык кылулары иң нәфрәтле гамәлләрдән булып тора. Һәм ул ике мәхәббәт иясен дәимән вә гомерлеккә аерырга тырыша»[12]

## Күп хатынлык хакында

– Пәйгамбәребезнең ﷺ унбер хатыны бар иде, икесе ул исән вакытта вафат булды — Хәдиҗә бинт Хуәйлид һәм Зәйнәб бинт Хузәймә. Пәйгамбәребез ﷺ вафат булганда, аның тугыз хатыны калды: Гаишә бинт Әбү Бәкер, Хәфса бинт Гомәр, Үммү Сәләмә Һинд бинт Әбү Үмәййә, Сәүдә

11 әр-Рум 21

12 Ибен әл-Кайим «Раудаһ әл-Мүхиббин»ның «Дәүә әл-Мүхиббин» бүлеге

бинт Зәмга, Үммү Хәбибә Рамлә бинт Әбү Сүфьян, Зәйнәб бинт Җәхш, Мәймүнә бинт әл-Хәрис, Җүәйрия бинт әл-Хәрис, Сафия бинт Хүйәй бинт Әхътаб.

– Әбү Бәкернең ﵁ кәнизәкләрдән тыш, тормыш буена биш хатыны булды.

– Гомәр бин әл-Хаттабның ﵁ тормыш буена тугыз хатыны булды.

– Госман бин Гаффанның ﵁ тормыш буена җиде яки сигез хатыны булды.

– Гали бин Әбү Талибның ﵁ тормыш буена сигез хатыны булды.

– Талхә бин Гобәйдуллаһның ﵁ тормыш буена унбер хатыны булды.

– Зөбәер бин Гауүәмнең ﵁ тормыш буена унбер хатыны булды.

– Сагьд бин Әбү Үәккасның ﵁ тормыш буена унбер хатыны булды.

– Габдуррахмән бин Гауфның ﵁ тормыш буена унбиш хатыны булды.

– Сәгыйд бин Зәйднең ﵁ тормыш буена ун хатыны булды.

– Габдуллаһ бин Гомәрнең ﵁ тормыш буена алты хатыны булды. һ.б.

وَإِنْ خِفْتُمْ أَلَّا تُقْسِطُوا فِي الْيَتَامَى فَانْكِحُوا مَا طَابَ لَكُمْ مِنَ النِّسَاءِ مَثْنَى وَثُلَاثَ
وَرُبَاعَ فَإِنْ خِفْتُمْ أَلَّا تَعْدِلُوا فَوَاحِدَةً أَوْ مَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ ذَلِكَ أَدْنَى أَلَّا تَعُولُوا

Мәгънәсе: **«Әгәр дә, ятимнәрне гаделлек белән тәрбия кылырга курыксагыз, күңелегезгә хуш килгән башка хатын-кызлардан икешәр, өчәр һәм дүртәрне үзегезгә никах кылып алыгыз. Әгәр гаделлек кыла алмабыз дип курыксагыз, бергә генә никахланыгыз яки сатып алган кәнизәкләрегез җитәр. Бу (бергә генә никахлану яки сатып алган кәнизәк белән канәгатьләнү) гаделсезлектән саклануыгыз өчен хәерлерәктер»**[13]

13 ән-Нисә 3

٢٠٥٠ ــ عَنْ مَعْقِلِ بْنِ يَسَارٍ قَالَ: جَاءَ رَجُلٌ إِلَى النَّبِيِّ ﷺ فَقَالَ إِنِّي أَصَبْتُ امْرَأَةً ذَاتَ حَسَبٍ وَجَمَالٍ وَإِنَّهَا لاَ تَلِدُ أَفَأَتَزَوَّجُهَا قَالَ لاَ ثُمَّ أَتَاهُ الثَّانِيَةَ فَنَهَاهُ ثُمَّ أَتَاهُ الثَّالِثَةَ فَقَالَ تَزَوَّجُوا الْوَدُودَ الْوَلُودَ فَإِنِّي مُكَاثِرٌ بِكُمُ الأُمَمَ (سنن أبي داود صحيح)

Мәгънәсе: Мәгъкыйл бин Ясәр ﵁ әйтте:

— «Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ янына бер кеше килде һәм әйтте: «Мин затлы нәселдән булган һәм бик чибәр хатын-кызны очраттым, ләкин ул бала тапмый, аңа өйләнимме?». Пәйгамбәребез ﷺ: «Юк!», — диде. Шуннан соң бу кеше икенче тапкыр килеп сорады, анда да пәйгамбәребез ﷺ аны тыйды. Бераз вакыттан соң өченче тапкыр килде, һәм пәйгамбәребез ﷺ аңа: «Ирләрен ярата торган һәм күп бала табучы хатыннарга өйләнегез! Хакыйкатьтә, мин сезнең башка өммәтләргә караганда күплегегез белән горурланам», — диде.

١٦٣١ ــ عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ ﷺ قَالَ إِذَا مَاتَ الإِنْسَانُ انْقَطَعَ عَنْهُ عَمَلُهُ إِلاَّ مِنْ ثَلاَثَةٍ إِلاَّ مِنْ صَدَقَةٍ جَارِيَةٍ أَوْ عِلْمٍ يُنْتَفَعُ بِهِ أَوْ وَلَدٍ صَالِحٍ يَدْعُو لَهُ (مسلم)

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Әгәр дә кеше үлсә, өч әйбердән башка аның барча гамәлләре дә киселә (туктала): савабы килеп торучы садәка, яки файдаланыла торган гыйлем, яки аңа дога кылучы изге бала».

٥٠٦٨ ــ عَنْ أَنَسٍ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُ أَنَّ النَّبِيَّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ كَانَ يَطُوفُ عَلَى نِسَائِهِ فِي لَيْلَةٍ وَاحِدَةٍ وَلَهُ تِسْعُ نِسْوَةٍ (البخاري)

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәлик ﵁ әйтте:

— «Пәйгамбәребезнең ﷺ тугыз хатыны бар иде, һәм ул бер төн эчендә хатыннарын әйләнеп чыга иде».

١٤٦٩ ــ عَنْ عَبْدِ اللَّهِ بْنِ عَمْرٍو أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: الدُّنْيَا مَتَاعٌ وَخَيْرُ مَتَاعِ الدُّنْيَا الْمَرْأَةُ الصَّالِحَةُ (مسلم)

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гамр бин әл-Гастан ﵁; Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Дөнья ул – ләззәтлек, һәм андагы иң хәерле ләззәтлек, ул – изге хатын».

٣٩٣٩ – عَنْ أَنَسٍ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ: حُبِّبَ إِلَيَّ مِنْ الدُّنْيَا النِّسَاءُ وَالطِّيبُ وَجُعِلَ قُرَّةُ عَيْنِي فِي الصَّلَاةِ (سنن النسائي، تحقيق الألباني: حسن صحيح)

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәликтән ﵁; Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Миңа бу дөньядан хатын-кызлар һәм хушбуй сөйкемле булды, ә күземнең тынычлыгы намазда иде».

٣١٢١ – عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ عَنْ النَّبِيِّ ﷺ قَالَ: ثَلَاثَةٌ كُلُّهُمْ حَقٌّ عَلَى اللَّهِ عَزَّ وَجَلَّ عَوْنُهُ الْمُجَاهِدُ فِي سَبِيلِ اللَّهِ وَالنَّاكِحُ الَّذِي يُرِيدُ الْعَفَافَ وَالْمُكَاتَبُ الَّذِي يُرِيدُ الْأَدَاءَ (سنن النسائي، حسن)

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁; Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Өч төрле кешене Аллаһ тәгалә Үзенең ярдәменнән калдырмый; Аллаһ юлында сугышучы мөҗәһид, үзен зинадан һәм башка төрле хәрамнардан сакларга тырышып өйләнергә теләүче һәм үзен хуҗасыннан сатып алырга теләүче кол».

**Сахәбәләрдән кайбер әсәрләр:**

٥٠٦٩ – عَنْ سَعِيدِ بْنِ جُبَيْرٍ قَالَ: قَالَ لِي ابْنُ عَبَّاسٍ:هَلْ تَزَوَّجْتَ؟ قُلْتُ: لا. قَالَ: فَتَزَوَّجْ فَإِنَّ خَيْرَ هَذِهِ الْأُمَّةِ أَكْثَرُهَا نِسَاءً (البخاري)

Мәгънәсе: Сәгыйд бин Җубәйрдән ﵁ риваять ителә; ибен Габбас ﵁ миннән сорады:

— «Син өйләндеңме?». Мин әйттем: «Юк». Шуннан соң ул миңа: «Өйлән! Хакыйкатьтә, бу өммәтнең иң хәерле кешесе – күп хатынлысы», — диде».

عن عبد الله قال: لَوْ لَمْ يَبْقَ مِنْ الدَّهْرِ إِلَّا لَيْلَة لأَحْبَبْتُ أَنْ يَكونَ لِي فِي تِلْكَ اللَّيْلَة امْرَأة (مصنف ابن أبي شيبة صحيح عن ابن مسعود)

Мәгънәсе: Габдулаһ бин Мәсгуд әйтте:

— «Әгәр дә бу гомердән бер генә төн калса, миндә ул төнне хатын-кыз булуын теләр идем».

Бу дәлилләр барысы да күп хатынлык мөстәхәб икәнлегенә дәлил булып ишәрат кылалар. Бу мөстәхәбнең асылы, әгәр дә ир-ат хатыннары арасында гаделлеккә кадир булса, чөнки Аллаһ тәгалә Коръәндә: **«Әгәр гаделлек кыла алмабыз дип курыксагыз»,** — диде. Һәм шулай ук, әгәр дә ир алар белән фетнәләнермен дип курыкмаса, һәм алар сәбәпле Аллаһның фарызларын вә хокукларын үтәүдә ваемсызланырмын дип уйламаса гына. **«Әй мөэминнәр! Тәхкыйк сезнең хатыннарыгыздан һәм балаларыгыздан бардыр сезгә дошман булганнары, алардан сакланыгыз, гафил булмагыз!»**[14]

Шулай ук, әгәр дә ул аларны изгелеккә өндәп начарлыктан тыярга, вә матди яктан көче җитә торган булса. **«Никахлану өчен мал таба алмаган ярлы кешеләр сабыр итсеннәр Аллаһ аларга байлык биргәнгә чаклы, һәм зинадан саклансыннар»**[15] Аллаһу әгъләм.

## Кыямәт билгеләреннән – хатын-кызларның күбәюе

٥٢٣١ – عَنْ أَنَسٍ ﷺ قَالَ لأُحَدِّثَنَّكُمْ حَدِيثًا سَمِعْتُهُ مِنْ رَسُولِ اللَّهِ ﷺ لاَ يُحَدِّثُكُمْ بِهِ أَحَدٌ غَيْرِى، سَمِعْتُ رَسُولَ اللَّهِ ﷺ يَقُولُ «إِنَّ مِنْ أَشْرَاطِ السَّاعَةِ أَنْ يُرْفَعَ الْعِلْمُ، وَيَكْثُرَ الْجَهْلُ وَيَكْثُرَ الزِّنَا، وَيَكْثُرَ شُرْبُ الْخَمْرِ، وَيَقِلَّ الرِّجَالُ، وَيَكْثُرَ النِّسَاءُ حَتَّى يَكُونَ لِخَمْسِينَ امْرَأَةً الْقَيِّمُ الْوَاحِدُ» (البخاري)

Әнәс ﷺ әйтте: Мин сезгә, миннән башка беркем дә сөйләмәс пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисен сөйлим. Мин аның болай дип әйткәнен ишеттем:

---

14 әт-Тәгабүн 14

15 ән-Нур 33

— «Дөреслектә, Кыямәт Көненең билгеләреннән: гыйлемнең юкка чыгуы; җәһиллекнең күбәюе; зинаның күбәюе; хамер эчүнең күбәюе; ирләрнең азаюы һәм хатын-кызларның күбәюе, хәтта илле хатынга бер ир-ат булачак».

## Шәйх Әш-Шәнкыйтыйның күп хатынлык турындагы сүзе

Шәйх Әш-Шәнкыйтый үзенең «Әдъүә әл-Бәян» дип исемләнгән Коръән тәфсире китабында болай диде:

— «Коръән Кәримнең хаклыкны билгеләүдә булган үслүбеннән — дүрт хатын алуны рөхсәт вә мөбах кылуы. Инде ир-ат хатыннар арасында гаделлекне булдыра алмаудан курыкса, бу вакытта бер хатын яки кәнизәк белән канәгатьләнергә тиешле.

Бершиксез, барча акыллы кешегә дә мәгълүм булуынча, иң гадел вә иң дөрес юл, күп хатынлыкның рөхсәт ителүе булып тора:

1) Билгеле булганча, хатын-кызның күрем вакытлары була вә аларга гына хас булган төрле чирләр белән авырый. Бу нәрсәләр ир-атка зыян китерә, чөнки ул күпчелек вакыт якынлык кылуга, өммәтебезне арттыруга әзер булып тора.

2) Аллаһ тәгаләнең хикмәте, гадәттә ир-атлар хатыннарга караганда азрак, һәм үлемгә күбрәк дучар булучылар, сугышлар вә башка сәбәпле. Әгәр дә, ир-ат бер хатын гына ала торган булса, ул вакытта бик күп хатын-кызлар ирсез калып фәхешлеккә, зинага, бозыклыкка, әдәпсезлеккә вә төрле чирләргә юл ачучы булалар.

3) Гадәттә, хатын-кызларның күпчелеге кияүгә чыгарга әзер, ә ирләрнең күпчелеге матди яктан хатыннарын, балаларын, гаиләрен карарга әзер түгелләр. Шулай

булгач, өйләнеп гаиләләрен тәэмин итәргә әзер булган ирләргә караганда, кияүгә чыгарга әзер булган хатын-кызлар күбрәк, чөнки хатын-кызның өстендә гаиләне карау белән бәйле булган бер бурычы да юк. Ә инде, өйләнергә әзер булган ир-атлар бер хатын белән генә чикләнсәләр, ул вакытта кияүгә чыгарга әзер булган күпчелек хатын-кызларга нишләргә?!

Әгәр дә ир-ат гадел була алудан курыкса, ул вакытта бер хатын яки кәнизәк белән генә канәгатьләнергә тиеш: **«Тәхкыйк Аллаһ тәгалә һәр囲 эштә гадел булырга һәм яхшы эшләр кылырга боера»**[16] Шулай ук, хатыннар арасында шәригать хокукларын үтәүдә бер хатынны икенчесенә караганда артык күрергә, берсенә генә авышырга ярамый: **«Бер хатыннарыгыз ягына бөтенләй авышып, икенче хатыннарыгызны нәүбәттән өлешсез итеп, ирсез хатыннар кебек калдырмагыз!»**[17] Ә инде, табигый мәхәббәт белән бәйле булган берсен икечесенә караганда ныграк ярату кебек мәсьәләдә, болар кешенең мөмкинчелегеннән тормый, һәм бу ошбу аятьне аңлата: **«Хатыннарыгыз арасында гадел була алмассыз»**[18] яки, яратуда, күңелнең вә йөрәкнең берсенә күбрәк авышуында гадел була алмассыз.

Коръән Кәрим күп хатынлыкны, хатын-кызның кияүгә чыгудан мәхрүм булмауы файдасы өчен дә, ир-ат бер хатын белән генә торып зыяннан саклану файдасы өчен дә һәм өммәтебезнең саны артып *Аллаһ* тәгаләнең сүзе өстен чыгуы файдасы өчен дә, рөхсәт итте. Бу *Аллаһ*ның шәригате һәм аны акылсыз, көферлек караңгылыгы белән капланган кеше генә инкяр итә. Хатыннарның дүрт булуында да *Аллаһ*ның хикмәте, чөнки бу урталык, күп тә түгел, аз да түгел, ә бәлки кешенең көч-кодрәте җиткән кадәр генә, һәм бу *Аллаһ*ка яхшы билгеле»[19].

16 ән-Нәхел 90
17 ән-Нисә 129
18 ән-Нисә 129
19 Әдъүә әл-Бәян 3/377

# Җәннәттә күп хатынлык

١٦٦٣ – عَنْ الْمِقْدَام بْنِ مَعْدِي كَرِبَ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم: «لِلشَّهِيدِ عِنْدَ اللَّهِ سِتُّ خِصَالٍ يُغْفَرُ لَهُ فِى أَوَّلِ دَفْعَةٍ وَيَرَى مَقْعَدَهُ مِنَ الْجَنَّةِ وَيُجَارُ مِنْ عَذَابِ الْقَبْرِ وَيَأْمَنُ مِنَ الْفَزَعِ الأَكْبَرِ وَيُوضَعُ عَلَى رَأْسِهِ تَاجُ الْوَقَارِ الْيَاقُوتَةُ مِنْهَا خَيْرٌ مِنَ الدُّنْيَا وَمَا فِيهَا وَيُزَوَّجُ اثْنَتَيْنِ وَسَبْعِينَ زَوْجَةً مِنَ الْحُورِ الْعِينِ وَيُشَفَّعُ فِى سَبْعِينَ مِنْ أَقَارِبِهِ» (أخرجه الترمذي، وقال: حديث صحيح غريب)

Мәгънәсе: Әл-Микъдәм бин Мәгьдий Кәрибтән ﵁; Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Шәһидне Аллаһ хозурында алты табыш көтә: Иң беренче тамчы каны таму белән барча гөнаһлары да ярлыкана; Җәннәттәге урыны күрсәтелә; Кабер газабыннан котыла; Кыямәт көнендә имин була; Башына таҗ кидерелә, ул таҗның якуты бу дөньядан һәм дөньяда булган барча нәрсәдән дә хәерлерәк; Җитмеш ике хур кызына өйләндерелә һәм җитмеш туганына шәфәгать кыла».

٤٨٧٩ – عَنْ أَبِى بَكْرِ بْنِ عَبْدِ اللَّهِ بْنِ قَيْسٍ عَنْ أَبِيهِ أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ ﷺ قَالَ: «إِنَّ فِى الْجَنَّةِ خَيْمَةً مِنْ لُؤْلُؤَةٍ مُجَوَّفَةٍ، عَرْضُهَا سِتُّونَ مِيلاً، فِى كُلِّ زَاوِيَةٍ مِنْهَا أَهْلٌ، مَا يَرَوْنَ الآخَرِينَ يَطُوفُ عَلَيْهِمُ الْمُؤْمِنُونَ» (البخاري)

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Кайстән риваять итела; Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Дөреслектә, Җәннәттә эче куыш энҗедән чатыр бар, аның һәрбер тарафында мөэминнргә хәзерләнгән хатыннары бар, һәм алар башкаларын күрмиләр. Аларның яннарына мөэминнәр йөрерләр».

## Җәннәттә мөэминнәр арасында бернинди ачу һәм нәфрәтлек булмый

وَنَزَعْنَا مَا فِي صُدُورِهِمْ مِنْ غِلٍّ إِخْوَانًا عَلَى سُرُرٍ مُتَقَابِلِينَ

Аллаһ тәгалә әйтте: **«Без аларның күкрәкләрендә булган ачуны юк итәрбез, һәм алар ятакларда кырын сөялеп бер-беренә капма-каршы карап ятырлар»[20]**

٣٢٤٥ – عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ ﵁ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ «أَوَّلُ زُمْرَةٍ تَلِجُ الْجَنَّةَ صُورَتُهُمْ عَلَى صُورَةِ الْقَمَرِ لَيْلَةَ الْبَدْرِ، لاَ يَبْصُقُونَ فِيهَا وَلاَ يَمْتَخِطُونَ وَلاَ يَتَغَوَّطُونَ، آنِيَتُهُمْ فِيهَا الذَّهَبُ، أَمْشَاطُهُمْ مِنَ الذَّهَبِ وَالْفِضَّةِ، وَمَجَامِرُهُمُ الأَلُوَّةُ، وَرَشْحُهُمُ الْمِسْكُ، وَلِكُلِّ وَاحِدٍ مِنْهُمْ زَوْجَتَانِ، يُرَى مُخُّ سُوقِهِمَا مِنْ وَرَاءِ اللَّحْمِ، مِنَ الْحُسْنِ، لاَ اخْتِلاَفَ بَيْنَهُمْ وَلاَ تَبَاغُضَ، قُلُوبُهُمْ قَلْبٌ وَاحِدٌ، يُسَبِّحُونَ اللَّهَ بُكْرَةً وَعَشِيًّا» (البخاري)

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁; Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Җәннәткә беренче төркем белән керүчеләрнең сурәтләре тулган ай төнендәге ай шикелле булыр. Җәннәттә алар төкермәсләр, сеңгермәсләр һәм тәрәтләнмәсләр. Анда аларның савытлары алтыннан, тараклары — алтыннан һәм көмештән, миҗмәраларында[21] әлүүәһ[22] булыр һәм тирләре миск[23] булыр. Аларның һәрберсенең ике хатыны булыр һәм аларның чибәрлегеннән тән аша аяк сөякләренең җелеге күренер. Җәннәт әһелләре арасында бернинди хыйлаф та, нәфрәт тә булмас, аларның йөрәкләре бер йөрәк кебек булыр һәм алар Аллаһны иртәсен дә, кичен дә тәсбихләрләр».

---

20 әл-Хиҗер 47

21 Хушбуй агачын яндырып төтәсли торган тимер савыт

22 Һиндстан хушбуй агачы кебек көйрәтеп хуш төтен чыгара торган матдә

23 Хушбуй

## Хатыннарга мәһернең һәм туйның төрлечә булуы рөхсәт ителә

٢١٠٧ – عَنْ أُمِّ حَبِيبَةَ أَنَّهَا كَانَتْ تَحْتَ عُبَيْدِ اللَّهِ بْنِ جَحْشٍ فَمَاتَ بِأَرْضِ الْحَبَشَةِ فَزَوَّجَهَا النَّجَاشِيُّ النَّبِيَّ ﷺ وَأَمْهَرَهَا عنه أَرْبَعَةَ آلاَفٍ وَبَعَثَ بِهَا إِلَى رَسُولِ اللَّهِ ﷺ مَعَ شُرَحْبِيلَ ابْنِ حَسَنَةَ (سنن أبي داود صحيح)

Мәгънәсе: Үммү Хәбибәдән риваять ителә:

— «Үммү Хәбибә Гүбәйдуллаһ бин Җәхшның хатыны иде. Ире Хәбәшә җирендә үлгәннән соң,ән-Нәҗәший аны пәйгамбәребезгә ﷺ кияүгә бирде һәм расүлебез ﷺ өчен үзеннән дүрт мең (дирһәм[24]) мәһер бирде, һәм аны Шүрахбил бин Хәсәнәһ белән бергә пәйгамбәребезгә ﷺ җибәрде»

عَنْ أَنَسِ بْنِ مَالِكٍ أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ ﷺ أَعْتَقَ صَفِيَّةَ، وَجَعَلَ عِتْقَهَا صَدَاقَهَا

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәликтән ؓ риваять ителә:

— «Пәйгамбәребез ﷺ Сафияны азат итте, һәм шушы азатлыгын аңа мәһер кылды» (Бохари 5086)

٥١٧١ – عَنْ ثَابِتٍ قَالَ ذُكِرَ تَزْوِيجُ زَيْنَبَ ابْنَةِ جَحْشٍ عِنْدَ أَنَسٍ فَقَالَ مَا رَأَيْتُ النَّبِيَّ ﷺ أَوْلَمَ عَلَى أَحَدٍ مِنْ نِسَائِهِ مَا أَوْلَمَ عَلَيْهَا أَوْلَمَ بِشَاةٍ (البخاري)

Мәгънәсе: Сәбит әйтте:

— «Бервакыт Әнәс бин Мәлик янында, пәйгамбәребез ﷺ белән Зәйнәб бинт Җәхшның өйләнешүе хакында искә алынгач, ул: «Мин беркайчан да пәйгамбәребезнең ﷺ Зәйнәбкә ясаган мәҗлесе кебек, башка хатыннарына ясаган мәҗлесен күрмәдем, ул Зәйнәбкә бер сарык белән мәҗлес кылды», — диде».

٥١٧١ – عَنْ صَفِيَّةَ بِنْتِ شَيْبَةَ قَالَتْ: أَوْلَمَ النَّبِيُّ - صلى الله عليه وسلم - عَلَى بَعْضِ نِسَائِهِ بِمُدَّيْنِ مِنْ شَعِيرٍ (البخاري)

---

24 Бер дирһәм = 3,125гр. көмеш

Мәгънәсе: Сафия бинт Шәйбәһ әйтте:

— «Пәйгамбәребез ﷺ кайбер хатыннарына ике мүдд[25] арпа белән туй мәҗлесе ясады»

Пәйгамбәребезнең ﷺ Сафияга өйләнүе хакында Әнәс رضي الله عنه болай диде:

— «Пәйгамбәребез ﷺ (Мәдинә белән Хәйбәр арасында) юлда чакта Үммү Сүләйм аның өчен Сафияны бизәп хәзерләде, һәм кич белән пәйгамбәребезгә ﷺ китерде. Икенче көнне иртә белән расүлебез кияү булгач, кешеләргә: «Кемнең (артык ризыгы) булса, безгә алып килсен!», — диде, һәм (җиргә) күн җәймәсен җәйде. Кемдер эремчек, кемдер кипкән хөрмә, ә кемдер май алып килде. Аннары алар ошбу ризыкларны бутап «хәйс» дип аталган ашамлык хәзерләделәр. Кешеләр рәхәтләнеп бу ризыкларны ашап, яннарындагы яңгыр суыннан җыелган күлдәвектән эчтеләр. Пәйгаймбәребезнең туй мәҗлесе шушылай булды»[26]

## Хатыннарның һәрберсенә аерым торак

**Ир-атка берничә хатынын бер йортта җыярга ярыймы?**

وَقَرْنَ فِي بُيُوتِكُنَّ

Мәгънәсе: **«Әй хатынныр! Өйләрегездә калыгыз!»[27]**

وَاذْكُرْنَ مَا يُتْلَى فِي بُيُوتِكُنَّ مِنْ آيَاتِ اللَّهِ

Мәгънәсе: **«Әй хатыннар! Өегездә укылган Аллаһның аятьләрен зикер итегез!»[28]**

---

25 Бер мүдд = 812,5гр

26 Мөслим 88-1365

27 әл-Әхзәб 33

28 әл-Әхзәб 34

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تَدْخُلُوا بُيُوتَ النَّبِيِّ إِلَّا أَنْ يُؤْذَنَ لَكُمْ

Мәгънәсе: **«Әй мөэминнәр! Пәйгамбәрнең йортларына рөхсәт сорамыйча кермәгез!»**[29]

Аллаһ тәгалә бу аятьтә **«йортына»** дип берлек санда әйтмәде, ә бәлки **«йортларына»** дип күплек санда әйтте.

وَاتَّقُوا اللَّهَ رَبَّكُمْ لَا تُخْرِجُوهُنَّ مِنْ بُيُوتِهِنَّ

Мәгънәсе: **«Раббыгыз Аллаһка тәкъва булыгыз! Талак кылгач, аларны (хатыннарыгызны) торган өйләреннән чыгармагыз!»**[30]

Әнәстән ﷺ риваять ителә:

— «Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ үзенең хатыннарының берсендә булганда, мөэминнәрнең аналары булган пәйгамбәребезнең икенче бер хатыны аңа куштабак белән ризык җибәрде. Пәйгамбәребез ﷺ булган йорттагы хатыны, ризык алып килгән хезмәтченең кулына сукты да, куштабак төшеп китеп ватылды. Пәйгамбәребез ﷺ савытның ватыкларын җыйды да, шунда ризыкны кире салды һәм: «Анагыз көнләште», — диде. Шуннан соң, савыт ватылган йорттан икенче ватылмаган савыт биргәнчегә кадәр хезмәтчегә көтеп торырга кушты, ә инде төзек савыт биргәч, ватылган савытны ватучы хатынының йортында калдырды»[31]

Бу һәм башка Бохарида, Мөслимдә вә сөннәт җыентыкларында килгән хәдисләр, хатыннарның аерым торакларда торуларына ишәрат кыла.

Бу мәсьәләгә карата Ибен Кудәмә Әл-Мугъний китабында (7/25-26) менә нәрсә әйтте:

— «Ир-ат хатыннарының ризалыгыннан тыш, аларны бер торакта (зур булсада, кечкенә булса да) җыеп торгыза алмый. Чөнки хатыннарның бер торакта торуларын-

29 әл-Әхзәб 53
30 әт-Таләкъ 1
31 Бохари 5225, 2481

да, алар арасында дошманлашу, көнчеллек, талашу, сугышу, шулай ук ир хатыннары белән йокларга теләсә дә, бер-берсен ишетү вә күрү зыяны бар.

Әгәр дә хатыннары риза булса, бу вакытта рөхсәт ителә. Чөнки бу аларның хакы һәм алар теләсәләр ризалык белдерәләр. Шулай ук, ир хатыннарының араларында йоклый ала, ләкин берсен-берсе күреп торган килеш якынлык кыла алмый, хәтта хатыннары риза булса да, чөнки мондый бозыклыкка вә оятсызлыкка аларның ризалыгы дөрес түгел.

Әгәр аларны бер йортта торгызып аерым-аерым тораклар бирсә, бертөрле булу шарты белән рөхсәт ителә»

Әл-Куртубийның сүзләре: «Ризалыкларыннан тыш аларны бер йортта җыеп торгыза алмый». һ.б.

## Пәйгамбәребезнең ﷺ һәм хатыннарының яңа килен каршылагандыгы әхлаклары

٤٧٩٤ – عَنْ أَنَسٍ ﵁ قَالَ: أَوْلَمَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ حِينَ بَنَى بِزَيْنَبَ ابْنَةِ جَحْشٍ فَأَشْبَعَ النَّاسَ خُبْزًا وَلَحْمًا ثُمَّ خَرَجَ إِلَى حُجَرِ أُمَّهَاتِ الْمُؤْمِنِينَ كَمَا كَانَ يَصْنَعُ صَبِيحَةَ بِنَائِهِ فَيُسَلِّمُ عَلَيْهِنَّ وَيَدْعُو لَهُنَّ وَيُسَلِّمْنَ عَلَيْهِ وَيَدْعُونَ لَهُ... (البخاري)

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәликтән ﵁ риваять ителә:

— «Аллаһның расүле ﷺ Зәйнәб бинт Җәхшка өйләнгәндә мәҗлес ясады, һәм кешеләр анда ипи белән итне туйганчы ашадылар. Шуннан соң, ул өйләнү иртәсендәге кебек мөэминнәрнең аналарының бүлмәләренә юнәлде һәм аларга сәлам биреп дога кылды, алар да аңа сәлам биреп дога кылдылар...»

## Өйләнгәннән соң, ирдә булган хатында һәм саф кызда үткәреләсе көннәрнең микъдары

٥٢١٤ – عَنْ أَنَسٍ قَالَ: مِنَ السُّنَّةِ إِذَا تَزَوَّجَ الرَّجُلُ الْبِكْرَ عَلَى الثَّيِّبِ أَقَامَ عِنْدَهَا سَبْعًا وَقَسَمَ، وَإِذَا تَزَوَّجَ الثَّيِّبَ عَلَى الْبِكْرِ أَقَامَ عِنْدَهَا ثَلَاثًا ثُمَّ قَسَمَ (البخاري)

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәлик ﵁ әйтте:

— «Әгәр дә ир кеше хатыны булып (икенчегә, яки өченчегә, яки дүртенчегә) саф кызга өйләнсә, аңарда җиде көн тоташтан кала ә аннары тигез итеп дәвам итә. Әгәр ул кияүдә булган хатын-кызга өйләнсә, аңарда өч көн тоташтан кала ә аннары тигез итеп дәвам итә»

Ибен Кудәмә әйтте: «Ир-атка ике хатын-кызга берьюлы өйләнергә мәкруһ санала. Чөнки, ул аларның беренче көннәрдә тиешле хакларын үти алмыйча, аларга зыян китерәчәк. Әгәр инде берьюлы икегә өйләнсә, алар арасында шобага салып башта берсенең тиешле көннәрен үти, аннары икенчесенең тиешле көннәрен үтәп бетерә. Шуннан соң, алар арасында көннәрне тигез итеп дәвам итә»

## Хатыннар арасын бүлүдә тигезлекне саклау

وَعَاشِرُوهُنَّ بِالْمَعْرُوفِ

Мәгънәсе: **«Хатыннар белән игелекле булыгыз»**[32]

فَلَا تَتَّبِعُوا الْهَوَى أَنْ تَعْدِلُوا وَإِنْ تَلْوُوا أَوْ تُعْرِضُوا فَإِنَّ اللَّهَ كَانَ بِمَا تَعْمَلُونَ خَبِيرًا

Мәгънәсе: **«Гаделлектән тайпылмас өчен нәфсегә, һәвәскә иярмәгез. Әгәр дә сез авышсагыз яки баш тартса-**

32 эн-Нисэ 19

**гыз, дөреслектә, Аллаһ сезнең кылган гамәлләрегездән хәбәрдәр»**[33]

وَلَا يَجْرِمَنَّكُمْ شَنَآنُ قَوْمٍ عَلَى أَلَّا تَعْدِلُوا اعْدِلُوا هُوَ أَقْرَبُ لِلتَّقْوَى وَاتَّقُوا اللَّهَ إِنَّ اللَّهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ

Мәгънәсе: **«Кешеләрнең нәфрәтләре сезнең гаделлектән тайпылуыгызга сәбәп булмасын. Гадел булыгыз! Чөнки, ул тәкъвалыкка якынрак. Аллаһка тәкъва булыгыз! Дөреслектә, Аллаһ сезнең кылган гамәлләрегезне белүче»**[34]

١٤٦٠ – عَنْ أُمِّ سَلَمَةَ أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ ﷺ لَمَّا تَزَوَّجَ أُمَّ سَلَمَةَ أَقَامَ عِنْدَهَا ثَلَاثًا وَقَالَ «إِنَّهُ لَيْسَ بِكِ عَلَى أَهْلِكِ هَوَانٌ إِنْ شِئْتِ سَبَّعْتُ لَكِ وَإِنْ سَبَّعْتُ لَكِ سَبَّعْتُ لِنِسَائِى» (مسلم)

Мәгънәсе: Үммү Сәләмәдән риваять итеlә; Пәйгамбәребез ﷺ Үммү Сәләмәгә өйләнгәч аңарда өч көн булды, һәм әйтте:

— «Синең әһелеңнән сиңа карата рәнҗетү юк. Әгәр дә теләсәң мин синең белән җиде көн үткәрәм, ләкин ул вакытта башка хатыннарым белән дә җидешәр көн үткәрәм»

Әнәс бин Мәлик ﷺ әйтте:

— «Пәйгамбәребезнең ﷺ тугыз хатыны бар иде. Ул алар арасын көннәр буенча бүлгәндә, беренчесенә тугызынчы көнне генә ирешә иде. Алар барысы да һәр кичне пәйгамбәребез ﷺ буласы хатынының йортында җыелалар иде. Ул Гаишә йортында иде һәм анда Зәйнәб килде. Пәйгамбәребез ﷺ аңа кулын сузгач, Гаишә: «Бу бит Зәйнәб!», — диде, һәм ул ﷺ кулын кире алды. Алар (Гаишә белән Зәйнәб) үзара сүз әйтешеп, хәтта бер-берсенә кычкырыша башладылар. Бу вакытта намазга камәт әйтелде. Янәшәдән узып барган Әбү Бәкер аларның та-

33 ән-Нисә 135
34 әл-Мәидә 8

вышын ишетеп: «Әй Аллаһның илчесе! Намазга чык, ә мин аларның авызларына балчык ыргытам», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ чыгып киткәч Гаишә әйтте: «Хәзер пәйгамбәребез намазын укыгач, Әбү Бәкер киләчәк һәм миңа аннан эләгәчәк». Пәйгамбәребез ﷺ намазын укып бетергәч, Гаишә янына Әбү Бәкер килде һәм аңа: «Ничек син шушылай эшли аласың?!», — дип, бик каты орышты»[35]

Пәйгамбәр ﷺ гаделлекә өндәп болай диде:

٢١٣٣ – عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ عَنِ النَّبِيِّ ﷺ قَالَ: «مَنْ كَانَتْ لَهُ امْرَأَتَانِ فَمَالَ إِلَى إِحْدَاهُمَا جَاءَ يَوْمَ الْقِيَامَةِ وَشِقُّهُ مَائِلٌ» (سنن أبي داود صحيح)

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁; Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Кемнең ике хатыны булып берсен икенчесенә караганда өстенрәк күрә икән, Кыямәт көнендә бер ягы кыйгайган хәлдә кубарылыр»

١٩٧١ – عَنْ عَائِشَةَ رضي الله عنها قَالَتْ: كَانَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ يَقْسِمُ فَيَعْدِلُ وَيَقُولُ: «اللَّهُمَّ هَذَا قَسْمِي فِيمَا أَمْلِكُ فَلَا تَلُمْنِي فِيمَا تَمْلِكُ وَلَا أَمْلِكُ» (ابن ماجه، تحقيق الألباني: ضعيف، لكن الطرف الأول منه حسن)

Расүлебез ﷺ хатыннары арасында гаделлекне саклый иде, һәм бу хакта Гаишә радый Аллаһү ганһә болай диде:

— «Расүл ﷺ хатыннары араларын тигез итеп һәм гаделлек белән бүлә иде, һәм: «Әй Аллаһ! Бу минем көчемнән булган тигезлек вә гаделлек, минем көчемнән булмаган, Үзеңнең кодрәтеңнән булган (йөрәкнең кемгә дә булса авышуы) өчен, мине битәрләмә», — дип әйтә иде».

عَنْ عَائِشَةَ رضي الله عنها: «أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم كَانَ إِذَا سَافَرَ أَقْرَعَ بَيْنَ نِسَائِهِ» (ابن ماجه ١٩٧٠، تحقيق الألباني: صحيح)

Гаишә радый Аллаһү ганһә әйтте:

— «Расүлебез ﷺ сәфәргә чыга торган булса, хатыннары арасында шобага сала иде».

---

35 Мөслим 1462

Пәйгамбәребез ﷺ авырган вакытта да хатыннары арасында гаделлекне сакларга тырыша иде, һәм: «Мин бүген кемдә? Мин иртәгә кемдә?», — дип, сорый торган иде[36].

Шулай ук, Гаишәдән риваять ителгән икенче хәдистә:

— «Пәйгамбәребез ﷺ әгәр дә сәфәргә чыгарга теләсә хатыннары арасында шобага сала иде, кайсысына туры килсә шунысы пәйгамбәребез ﷺ белән сәфәргә чыкты, һәм һәрбер хатынына көнен вә төнен тигез итеп бүлә иде, иллә-мәгәр Сәүдә бинт Зәмга гына пәйгамбәребезнең ризалыгын алыр өчен, үзенең көне белән төнен Гаишәгә бүләк итте», — диелде[37].

## Ир-атка хатыннарының йортларына барып йөрергә мөстәхәб санала, шулай ук, аларны үзенә чакыра ала

Пәйгамбәребез ﷺ авырган вакытында хатыннарыннан: «Мин бүген кемдә? Мин иртәгә кемдә?», — дип, сорый торган иде[38].

Бу хәдис пәйгамбәребез хатыннарының йортларына барып йөргәнлеген күрсәтә.

٢٠٨٤ – عَنْ جَابِرِ بْنِ عَبْدِ اللَّهِ أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ ﷺ قَالَ لَهُ «فِرَاشٌ لِلرَّجُلِ وَفِرَاشٌ لِامْرَأَتِهِ وَالثَّالِثُ لِلضَّيْفِ وَالرَّابِعُ لِلشَّيْطَانِ» (مسلم)

Мәгънәсе: Җәбир бин Габдуллаһтан ﷺ риваять ителә, аңа пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Ир-атка ятак, аның хатынына ятак, өченчесе — кунакка, ә дүртенчесе — шәйтанга»

Ир белән хатынның аерым ятаклары булуында бернинди дә зарар юк. Чөнки чирләгәндәге кебек, һәм баш-

---

36 Бохари 1389

37 Бохари 2688

38 Бохари 1389

ка очракларда аларның һәрберсе аерым ятакка мохтаҗ булулары мөмкин. Кайбер гыйлем ияләре бу хәдискә таянып, ирнең хатыны белән бергә йоклауы ләзем түгел дигән карашны исбатладылар, ләкин пәйгамбәребезнең башка хәдисләрен вә тормышын карасак, бергә йоклау хәерлерәк икәнлеге аңлашыла. Чөнки, әйтеп узганыбызча, аерым ятакның максаты чир һәм башка ихтыяҗ булгандагы сәбәпләр.

Өченче ятакның искә алынуы, ул сан чиген белдерү йөзеннән түгел, ә бәлки кунаклар өчен ятак булуының төрен белдерүдән. Шулай булгач, кунаклар күп килә торган гадәт булса, алар өчен ихтыяҗга карап берничә ятак булдыру инкяр ителми. Аллаһу әгъләм.

Дүртенче ятакка килгәндә, ул инде кирәкмәгәнгә йорт җиһазлары җыюны аңлата. Әгәр дә, кирәкмәгән ятак була икән, Аллаһ исемен искә алмыйча йортка кергән кебек, ул шәйтанның йоклау урыны булып кала. Шуңа да, имам Мөслимнең җыентыгында бу хәдис «Хаҗәттән тыш арткан ятакның һәм киемнең мәкруһлыгы хакында бүлек» дигән исем астында килде.

Шулай итеп, әгәр ир-ат аларның янына барып йөри торган булса, бу хәерлерәк. Ләкин, үзенә йорт булдырып хатыннарын берәм-берәм шунда чакыра торган булса, монда бернинди дә зарар юк, чөнки ир-ат хатынын кайда теләсә шунда күчерә ала, ә хатын аңа иярүче. Бу ирнең хакы.

## Ир-атның хатыннары төрле илдә булса

Бу хакта ибен Кудәмә болай диде: «Әгәр ир-атның ике хатыны ике илдә булса, ул алар арасында гадел булырга тиеш. Аларны ерак илләрдән сайлауы, аның алар каршындагы бурычларын бетерми. Ул хатыннарының көннәрендә һәрберсенең иленә барырга тиеш, яки инде

икесен дә бер илдә җыя. Әгәр дә бер хатыны килә алырга мөмкинчелек булып та килмәсә, ул вакытта иренең өстеннән бурычы төшә. Әгәр дә ир-ат һәрбер хатынын үз илләрендә көннәрен бүлергә теләп көнгә көн бүлә алмаса, ул вакытта илләрнең якынлыгына вә ераклыгына карап мөмкинчелегеннән чыгып айга – ай кебек, күбрәк яки азрак аерым бер мөтдәт билгели».

## Әгәр хатын иренең рөхсәтеннән башка сәфәргә чыгып китсә

Хатын-кызга иренең рөхсәтеннән тыш сәфәргә чыгарга ярамый. Әгәр дә хатын-кыз иренең рөхсәтеннән башка сәфәргә чыгып китсә, аны көннәр ягыннан бүлү дә, тәэмин итү дә ир өстеннән төшә. Чөнки, көннәрне бүлү һәм тәэмин итү ул хатын белән ләззәтләнү өчен, ә бу очракта хатын-кыз ирен моннан мәхрүм иткән була.

Ә инде иренең рөхсәте белән сәүдәгә, хаҗга, гомрәгә яки башка сәфәргә чыгып китсә, бу вакытта ике төрле караш: 1 – Көннәр дә, тәэмин итү дә ирнең өстеннән төшә. 2 – Ирнең рөхсәте сәбәпле хатынның хокуклары шул килеш кала. Без дөрес дип санаганы ирнең өстеннән төшә. Аллаһу әгъләм.

## Хатыннарны тигез тәэмин итү вәҗибме?

Бу мәсьәләдә гыйлем әһелләренең карашлары төрлегә бүленде. Аларның бер төркеме тигезлек вәҗиб дисә, икенче төркем мөстәхәб диде, ә инде өченчеләре бу мәсьәләдә тәфсыйлләү тиешле диделәр. Менә аларның кайбер сүзләре:

Ибен Кудәмә әйтте:

— «Әгәр дә ир-ат һәрбер хатынын иң кирәкле вәҗиб нәрсәләр белән тәэмин итсә, аңа аларны тәэмин итүдә һәм киендерүдә тигезлек саклау мәҗбүри түгел. Имам Әхмәд, ике хатыны булган бер ир хакында болай диде: «Әгәр дә бер хатыны җитешлелектә булса, бу ир хатыннарының икенчесен тегесенә караганда тәэмин итүдә дә, шәһвәттә дә һәм киендерүдә дә өстенрәк күрә ала. Тегесе киемдә җитешле булганда, монысына тегесенә караганда кыйммәтлерәк кием ала ала...»

әл-Куртубий әйтте: «Әгәр дә хатыннарының хәләтләре тигез булса, бу вакытта аларны тәэмин итүдә дә, киендерүдә дә гаделлек белән эш итә. Ә инде аларның хәләтләре төрлечә булса, бу очракта инде тигезлек белән тәэмин итү дә, киендерү дә вәҗиб булмый. Имам Мәлик, киемдә хатыннарның берсенә икенчесенә караганда өстенлек куюны рөхсәт итте».

Ибен Тәймия әйтте: «Ләкин, тәэмин итүдә һәм киендерүдә гаделлек кылу, пәйгамбәребезгә буйсыну йөзеннән сөннәт булып тора. Дөреслектә, кешеләр, пәйгамбәребезгә көннәрне бүлү вәҗиб идеме, әллә мөстәхәб идеме дигән сорауда төрле фикерле булуларына карамастан, ул хатыннары арасында көннәрне гаделлек белән бүлгән кебек, тәэмин итүне дә гаделлек белән бүлә иде. Шулай ук, кешеләр тәэмин итү вәҗибме әллә мөстәхәбме дигән мәсьәләдә аерылдылар. Вәҗиб булуы көчлерәк, һәм ул Китапка вә Сөннәткә муафыйкърак».

Әш-Шәүкәни әйтте: ««Берсенә авышу» дигән сүзләрдә, ирнең көченнән килә торган көннәрне бүлү, ашату вә киендерү кебек нәрсәләрдә хатыннарның берсеннән икенчесенә авышуны хәрам икәнлеген белгертә торган дәлил чагыла.

Бу гыйлем ияләренең кайбер фикерләре генә иде. Вәҗиб түгел дип әйтүчеләр Гаишәдән риваять ителгән ошбу хәдискә таяндылар:

— «Кешеләр пәйгамбәребезнең ﷺ ризалыгын алыр өчен, үзләренең бүләкләрен Гаишә көнендә китерергә тырышалар иде»[39]

Шулай ук, Бохарида (2581) һәм Мөслимдә (2442) китерелгән хәдисләрне әйтеп уздылар:

— «Пәйгамбәребезнең хатыннары ике төркем иделәр: Бер төркемдә Гаишә, Хәфса, Сафия һәм Сәүдә иде, ә икенчесендә Үммү Сәләмә һәм пәйгамбәребезнең ﷺ башка хатыннары иде.

Мөселманнар расүлебезнең Гаишәне яратканлыгын белә торган иделәр. Шуңа да, әгәр дә берәрсенең пәйгамбәргә бирәсе бүләге булса, пәйгамбәр Гаишәдә булганчыга кадәр бүләген бирүне соңлатып, расүл Гаишәнең өендә булганда бүләген җибәрә торган булды.

Бервакыт Үммү Сәләмә төркемендәге хатыннар, Үммү Сәләмәгә: «Аллаһның расүле белән сөйләш әле, ул кешеләргә: «кем пәйгамбәргә бүләк бирәсе килсә, хатыннарының кайсы йортында булса да, шунда бирсен», — дип әйтсен, диген. Үммү Сәләмә бу сүзләрне расүлебезгә барып әйтте, ләкин пәйгамбәребез аңа берничек тә җавап бирмәде. Шуннан соң алар аны җавап алганчы дип тагы ике тапкыр җибәрделәр. Пәйгамбәребез соңгысында Үммү Сәләмәгә: «Мине Гаишә белән теңкәмә тимәгез! Дөреслектә, Гаишәдән башка сезнең берегезнең ятагында булганда да миңа вахи иңгәне юк!», — диде. Үммү Сәләмә бу сүзләрне ишетеп: «Әй Аллаһның расүле! Мин сиңа авырту китергән өчен Аллаһка тәүбә итәм», — диде.

Шуннан соң, Үммү Сәләмә төркемендәге хатыннар пәйгамбәребезнең кызы Фәтыйманы чакыртып, расүлебезгә җибәрделәр. Фәтыймә рөхсәт сорап кергәч, пәйгамбәргә: «Дөреслектә, синең хатыннарың Аллаһ хакы өчен, үзләренә дә Гаишәгә булган кебек мөгамәлә итүеңне сорыйлар», — диде. Пәйгамбәребез аннан: «Әй

39 Мөслим 2441

кызым! Син мин яратканны яратмыйсыңмы әллә?», — дип сорады. Ул: «Әлбәттә, яратам», — диде. Шуннан соң расүлебез аңа: «Шулай булгач, моны да ярат!», — диде. Фәтыймә бу сүзләрне ишеткәч урыныннан торды да чыгып китте. Кайткач ул барысын да сөйләп бирде. Аны тагын җибәрергә теләгәннәр иде, ләкин ул каршы килде.

Шуннан соң алар Зәйнәб бинт Җәхшне җибәрделәр. Ул пәйгамбәребезгә тиешле хөрмәт күрсәтмичә: «Дөреслектә, синең хатыннарың Аллаһ хакы өчен, үзләренә дә Гаишәгә булган кебек мөгамәлә итүеңне сорыйлар», — диде. Зәйнәб Гаишәгә борылып аны бик каты сүгә башлады, ә пәйгамбәр Гаишә бирәр сүз әйтер микән дигәндәй карап торды. Гаишә җавабы белән Зәйнәбне тынычландырды, шуннан соң пәйгамбәребез аңа карады да: «Ул, Әбү Бәкер кебек», — диде».

Алар имам Әхмәд әйтүенчә, тәэмин итүдә вәҗиблек артык мәшкатьлеккә китерә диделәр.

Ә инде, вәҗиб диючеләр Коръәннән ошбу аятьләрне китерделәр:

**— «Гаделлектән тайпылмас өчен нәфсегә, һәвәскә иярмәгез. Әгәр дә сез авышсагыз яки баш тартсагыз, дөреслектә, Аллаһ сезнең кылган гамәлләрегездән хәбәрдәр»[40]**

**— «Кешеләрнең нәфрәтләре сезнең гаделлектән тайпылуыгызга сәбәп булмасын. Гадел булыгыз! Чөнки, ул тәкъвалыкка якынрак. Аллаһка тәкъва булыгыз! Дөреслектә, Аллаһ сезнең кылган гамәлләрегезне белүче»[41]**

Шулай ук, пәйгамбәребезнең ошбу хәдисе:

— «Кемнең ике хатыны булып берсен икенчесенә караганда өстенрәк күрә икән, Кыямәт көнендә бер ягы кыйгайган хәлдә кубарылыр»[42]

---

40 ән-Нисә 135

41 әл-Мәидә 8

42 Әбү Дауыд 2133

Ә инде беренчеләрнең хәдисләренә килгәндә, алар тигез тәэмин итүнең вәҗиб түгеллегенә бер катнашлары да юк дип, төрлечә җавап бирделәр.

Бу һәм башка фикерләрне караганнан соң, вәҗиб диючеләрнең карашы көчлерәк дип табылды, *Аллаһу* әгъләм.

## Хатыннар арасындагы көнчеллек

٥٢٢٩ ـ عَنْ عَائِشَةَ أَنَّهَا قَالَتْ مَا غِرْتُ عَلَى امْرَأَةٍ لِرَسُولِ اللَّهِ ﷺ كَمَا غِرْتُ عَلَى خَدِيجَةَ ، لِكَثْرَةِ ذِكْرِ رَسُولِ اللَّهِ ﷺ إِيَّاهَا وَثَنَائِهِ عَلَيْهَا ، وَقَدْ أُوحِيَ إِلَى رَسُولِ اللَّهِ ﷺ أَنْ يُبَشِّرَهَا بِبَيْتٍ لَهَا فِي الْجَنَّةِ مِنْ قَصَبٍ (البخاري)

Мәгънәсе: Гаишә радый *Аллаһу* ганһә әйтте::

— «Мин расүлебезнең ﷺ хатыннарыннан, Хәдиҗәдән көнләшкән кебек берсеннән дә көнләшмәдем. Чөнки ул ﷺ Хәдиҗәне күп искә ала вә мактый торган иде. Шулай ук, Хәдиҗәне Җәннәттә эче куыш энҗедән йорт белән шатландырырга дип, пәйгамбәребезгә вахи иңде».

عَنْ عَائِشَةَ رَضِيَ الله عَنْهَا قَالَتْ: أَتَيْتُ النَّبِيَّ ﷺ بِخَزِيرَةٍ قَدْ طَبَخْتُهَا لَهُ فَقُلْتُ لِسَوْدَةَ وَالنَّبِيُّ ﷺ بَيْنِي وَبَيْنَهَا: كُلِي، فَأَبَتْ، فَقُلْتُ: لَتَأْكُلِنَّ أَوْ لأُلَطِّخَنَّ وَجْهَكِ، فَأَبَتْ، فَوَضَعْتُ يَدِي فِي الْخَزِيرَةِ فَطَلَيْتُ وَجْهَهَا، فَضَحِكَ النَّبِيُّ ﷺ فَوَضَعَ بِيَدِهِ لَهَا وَقَالَ لَهَا: «الْطَخِي وَجْهَهَا»، فَفَعَلَتْ، فَضَحِكَ النَّبِيُّ ﷺ لَهَا ... ثم قال النبي ﷺ لهما: «قُومَا فَاغْسِلا وُجُوهَكُمَا» (أخرجه أبو يعلى (٧/٤٤٩ رقم ٤٤٧٦) وابن عساكر (٤٤/٩٠) قال الهيثمى (٤/٣١٦) رواه أبو يعلى ورجاله رجال الصحيح خلا محمد بن عمرو بن علقمة وحديثه حسن)

Гаишә радый *Аллаһу* ганһә әйтте:

— «Бервакыт мин пәйгамбәребезгә ﷺ «хазира»[43] дип аталган ризык пешереп алып килдем. Пәйгамбәребез ﷺ

43 Он, ит яки хайван мае һәм су кушылып пешерелгән шулпа

Сәүдә бинт Зәмга[44] белән икебезнең арабызда иде һәм мин Сәүдәгә: «Аша», — дидем. Ул кире какты. Мин аңа: «Син ашаячаксың, яки мин синең йөзеңә ошбу ризыкны буяячакмын!», — дидем. Ул тагын кире какты,шуннан соң мин кулымны үзем пешергән ризыкка тыктым да, аның йөзен буядым. Пәйгамбәребез ﷺ моны күреп көлеп җибәрде һәм кулын аңа (Сәүдәгә) куйды да: «Син дә аның йөзен шулай ук буя!», — диде. Сәүдә пәйгамбәребез ﷺ әйткәнчә эшләде. Моны күреп расүл ﷺ тагын көлеп җибәрде, шуннан соң аларга: «Торыгыз! Һәм битләрегезне юыгыз!», — диде».

Гаишә радый Аллаһу ганһә әйтте:

— «Әгәр дә, пәйгамбәребез юлга чыкса хатыннары арасында шобага сала иде. Бервакыт шобага Гаишә белән Хәфсага чыкты һәм алар икесе дә пәйгамбәр белән юлга чыктылар. Гадәттә кичен пәйгамбәребез Гаишә белән сөйләшә-сөйләшә юлын дәвам итә торган иде. Хәфса Гаишәгә: «Син бу кичтә минем дөямә утырмыйсыңмы? Ә мин синекенә утырам, шуннан соң нәрсә булганын карарбыз?», — диде. Гаишә: «Әлбәттә!», — диде дә, Хәфсаның дөясенә утырды, ә Хәфса Гаишәнекенә утырды. Пәйгамбәребез Хәфса утырган Гаишәнең дөясе янына килеп сәлам бирде, һәм ялга туктаганчы аның янәшәсендә юлын дәвам итте. Гаишә пәйгамбәребезне югалтты, һәм бик нык көнли башлады. Ялга туктагач ул аякларын хуш исле камышлар арасына тыкты да: «Әй Раббым! Мине чаян яки елан чаксын иде! Синең расүлең! Мин бит аңа бернәрсә дә әйтә алмыйм», — диде[45].

44 Пәйгамбәребезнең ﷺ икенче хатыны

45 Бохари 5211

## Хатын-кызга көндәшен ачуландырырга теләп, ире бирмәгән нәрсәне бирде дип әйтергә ярамый

٥٢١٩ – عَنْ أَسْمَاءَ أَنَّ امْرَأَةً قَالَتْ: يَا رَسُولَ اللَّهِ إِنَّ لِى ضَرَّةً، فَهَلْ عَلَىَّ جُنَاحٌ إِنْ تَشَبَّعْتُ مِنْ زَوْجِى غَيْرَ الَّذِى يُعْطِينِى؟ فَقَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ «الْمُتَشَبِّعُ بِمَا لَمْ يُعْطَ كَلاَبِسِ ثَوْبَىْ زُورٍ» (البخاري)

Мәгънәсе: Әсмә радый Аллаһу ганһә әйтте:

— «Бер хатын пәйгамбәребездән сорады: «Әй Аллаһның расүле! Минем көндәшем бар, әгәр дә мин ирем миңа бирмәгән нәрсәне бирде дип әйтеп мактансам, гөнаһ буламы?». Пәйгамбәребез ﷺ аңа: «Бирелмәгән нәрсәне аңа бирделәр дип әйтеп күз буяучы кеше, ике ялган кием киюче кебек», — диде[46].

Ягъни, кеше үзе кия торган киемнән башка киемне киеп, тышкы кыяфәте белән башкаларны үзенең сүзенә ышандырырга тели.

## «әл-Мисьяр» өйләнүе

Никахның шартлары үзгәрмичә, хатын-кыз үзенең теләге белән кайбер (матди, көннәрне бүлү кебек) хокукларыннан баш тартып, ире аның янында дәими булмыйча, вакыты-вакыты белән генә килеп йөри торган никах, **«әл-Мисьяр»** дип атала. «әл-Мисьяр» гарәп теленнән, күп йөрүче дигәнне аңлата.

Мондый өйләнүгә этәргән сәбәпләр:

– 22-23 яшьтән соң кияүгә чыкмыйча калган күп кенә карт кызлар; аерылган хатын-кызларның күп булуы; тол хатын-кызларның күп булуы.

46 Бохари 5219

– Күпчелек хатыннарның күп хатынлыкны кабул итә алмаулары. Шуның өчен дә ир-ат беренче хатыны белмәсен өчен шушындый өйләнүгә барырга мәҗбүр була.

– Ир-атның дәими рәвештә хатын-кыз белән рәхәтләнергә теләүе. Ә инде, гадәттә хатын-кыз олыгаю, яки берничә бала тапканнан соң, балалары белән мәшгуль булуы яки башка сәбәпле ире белән ятакта уйнап-рәхәтләнүдән читләшүе ихтимал.

– Ир-атларның өйләнүдә булган кайбер мәшәкатьләрдән һәм җаваплылыктан качырга теләүләре.

Ничек кенә булса да, бу төрле өйләнү күпчелек гыйлем ияләре тарафыннан рөхсәт ителә. Бигрәк тә безнең бозык җәмгыятьтә, мөселманнарның берничә хатынга өйләнеп хәрамнардан тыелу вә алардан ераклашу һәм мөселман өммәтен арттыру нияте белән булуы сәбәпле, күп хатынлык бигрәк тә хуп санала. Әле, ун ел элек мөселманнарның икенче хатын алулары гади татар-мөселманнар арасында зур җинаять кебек каралса, хәзерге көндә 3-4 хатынга өйләнү дә гадәти күренешкә әйләнеп бара, әлхәмдүлилләһ.

**«Яһүд һәм нәсаралар Аллаһ тәгаләнең нурын авызлары белән сүндермәкче булалар, ләкин Аллаһ моңа юл куймас, һәм кәферләргә ошамаса да Ул Үзенең нурын таралуны мөкәммәл кылыр. Ислам динен барча диннәрдән өстен кылыр өчен, Ул Үзенең расүлен һидәят вә хак дин белән җибәрде, гәрчә мөшрикләр ошатмасалар да»**[47]

*Әлхәмдүлилләһ! Аллаһның теләге һәм ярдәме илә изге гамәлләр тәмамлана.*

47 әт-Тәүбә 32-33

# ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз.....................................................................3
Ир һәм хатын арасында мәхәббәт серләре...................6
Күп хатынлык хакында.........................................10
Хатын-кызларның күбәюе Кыямәт билгесе...............14
Шәйх Әш-Шәнкыйтыйның күп хатынлык турындагы сүзе.......................................................................15
Җәннәттә күп хатынлык.......................................17
Җәннәттә мөэминәләр арасында берниндиачу һәм нәфрәтлек булмый.................................................18
Хатыннарга мәһернең һәм туйның төрлечә булуы рөхсәт ителә.....................................................................19
Хатыннарның һәрберсенә аерым торак....................20
Пәйгамбәребезнең ﷺ һәм хатыннарының яңа килен каршылагандыгы әхлаклары...................................22
Өйләнгәннән соң, ирдә булган хатында һәм саф кызда үткәреләсе көннәрнең микъдары...........................23
Хатыннар арасын бүлүдә тигезлекне саклау.............23
Ир-атка хатыннарының йортларына барып йөрергә мөстәхәб санала, ул аларны үзенә дә чакыра ала.........26
Ир-атның хатыннары төрле илдә булса....................27
Әгәр хатын иренең рөхсәтеннән башка сәфәргә чыгып китсә......................................................................28
Хатыннарны тигез тәэмин итү вәҗибме?...................28
Хатыннар арасындагы көнчеллек............................32
Хатын-кыз көндәшен ачуландырырга теләп, ире бирмәгән нәрсәне бирде дип әйтергә ярамый.............34
«әл-Мисьяр» өйләнүе............................................34